**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3610**
**28.05.2021**

«Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia)
региональ чемпионатының шәһәр
этабын үткәрү турында

Тәрбия процессын тормышка ашыруның сыйфатын күтәрү, шәһәр балалары һәм яшүсмерләрендә иҗади һәм лидерлык сыйфатларын үстерү максатыннан, Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5575 номерлы карары белән расланган «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) региональ чемпионатының (алга таба - чемпионат) шәһәр этабын үткәрергә.

2. Расларга:

1) региональ чемпионатның муниципаль этабы турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) чемпионатны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә чемпионатны үткәрү буенча чараларны финанслауны 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 169 604 (бер йөз алтмыш тугыз мең алты йөз дүрт) сум күләмендә тәэмин итәргә, 3 нче кушымтада каралганча.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 28 маендагы
3610 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia)
региональ чемпионатының муниципаль этабы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) региональ чемпионатының (алга таба – чемпионат) муниципаль этабы турында әлеге нигезләмә 2020/2021 уку елында «Юниорлар» категориясе буенча чемпионатны оештыру һәм үткәрү тәртибен, аны оештыру һәм методик яктан тәэмин итүне, чемпионатта катнашу һәм җиңүчеләрне һәм призерларны билгеләү тәртибен билгели. Чемпионат гомуми һәм өстәмә белем бирү оешмалары укучылары арасында үткәрелә.

2. Яр Чаллы шәһәре территориясендә чемпионатка әзерлекнең координаторы булып «5 нче балалар техник иҗат үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе (алга таба - «5 нче балалар техник иҗат үзәге» МАӨББУ) тора.

3. Чемпионатка әзерлек һәм аны үткәрүгә җитәкчелек итүне составы Башкарма комитет карары белән расланган оештыру комитеты гамәлгә ашыра.

2 бүлек. Чемпионатның максаты һәм бурычлары

1. Чемпионатның максаты булып гомуми һәм өстәмә белем бирү оешмаларында укучыларга иртә һөнәри юнәлеш бирү һәм һөнәри әзерлек нигезләре моделен төзү, экспертлар берләшмәсен һәм укучылар арасында һөнәри осталык нигезләре буенча ярышлар системасын формалаштыру тора.

2. Чемпионатның бурычлары:

1) заманча эшче һөнәрләрне популярлаштыру, җәмгыятьтә аларның абруен күтәрү;

2) техник иҗат өлкәсендә талантлы балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү;

3) югары технологияле предприятиеләрнең, индустрия объектларының, эшлекле үзәкләрнең, күргәзмә мәйданчыкларының, югары һәм урта махсус уку йортларының игътибарын, сәнәгать өчен кадрлар резервын әзерләү системасы субъектлары буларак, гомуми һәм өстәмә белем бирү оешмалары эшчәнлегенә җәлеп итү;

4) укучыларда конкрет һөнәри ситуацияләрдә бурычларны практик хәл итү һәм техник җайланмалар белән эшләү күнекмәләре үстерү;

5) мөстәкыйль эш күнекмәләрен камилләштерү, һөнәри фикерләүне үстерү һәм укучыларда башкарыла торган эшләре өчен җаваплылыкны арттыру.

3 бүлек. Чемпионатны үткәрү срогы һәм урыны

6. Чемпионат гомуми, өстәмә, һөнәри һәм югары белем бирү оешмалары (алга таба – мәгариф оешмалары) базасында 2020 елның октябреннән 2021 елның маена кадәр үткәрелә.

7. Белем бирү оешмалары чемпионатта катнашу өчен, үткәрү срогына кадәр кимендә 7 эш көне кала, электрон адрес буенча заявка һәм шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык җибәрәләр: gcdt5_chelny@mail.ru «Чемпионатта катнашу өчен заявка» тамгасы белән. Заявкалар формалаштыруны оештыру комитеты гамәлгә ашыра.

## 4 бүлек. Чемпионатның эчтәлеге

8. Чемпионатта катнашу кагыйдәләре:

1) команда составы һәрбер компетенция буенча чемпионатны уздыру таләпләре нигезендә билгеләнә;

2) «Прототиплаштыру» компетенциясендә катнашучылар (командалар) үзләре белән 3Д принтер өчен 1,75 мм, 750 грамм пластик булырга тиеш;

3) компетенциягә бирелгән заявкалар саны җитмәгән очракта, оештыру комитеты белән килешенеп, мәгариф оешмасына өстәмә квоталар тәкъдим ителергә мөмкин;

4) катнашучылар чемпионатны уздыру барышында алынган модельләр, схемалар һәм башка продуктларның фото- һәм видеосурәтләрен түләүсез нигездә файдалануга ризалык бирәләр.

3. Чемпионатның компетенцияләре:

1) санлы программа белән идарә итү станокларында фрезер эшләре;

2) санлы программа белән идарә итү станокларында токарь эшләре;

3) мобиль робот техникасы;

4) икмәк пешерү;

5) ресторан сервисы;

6) эшмәкәрлек;

7) медицина һәм социаль карау;

8) туризм;

9) прототиплаштыру;

10) график дизайн;

11) лазер технологияләре;

12) тавыш режиссурасы;

13) башлангыч сыйныфларда укыту;

14) төп һәм гомуми мәктәптә укыту;

15) мәктәптә музыка укыту;

16) кузов ремонты;

17) җиңел автомобильләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү;

18) металл буенча түбә ябу эшләре;

19) столяр эше;

20) физик культура, спорт һәм фитнес.

10. Әгәр анда катнашу өчен килгән заявкалар 4 тән ким булмаса, компетенция узган дип санала.

## 5 бүлек. Чемпионатны оештыру

11. Оештыру комитетының функцияләре:

1) Башкарма комитетның мәгариф идарәсенең тәрбия һәм өстәмә белем бирү бүлеге белгечләре белән килешенү буенча чемпионатны оештыру һәм үткәрүне координацияләүне гамәлгә ашыра;

2) чемпионатны үткәрүнең оештыру моделен билгели;

3) чемпионатның гомуми программасын, ачылу һәм ябылу тантаналарын әзерләү өчен җавап бирә;

4) чемпионат өчен эшләнгән техник тасвирламалар һәм инфраструктура битләренә туры китереп, чемпионатны уздыру өчен һәрбер компетенция буенча мәйданчыкларны тәэмин итү өчен җаваплы;

5) чемпионатның һәрбер компетенциясе буенча мәйданчыкта җиһазларның һәм куркынычсызлык техникасының эшкә сәләтлелеге өчен җаваплыны билгели;

6) конкурс участогы төзелешен техник тикшерүне тәэмин итә;

7) чемпионатны уздыруга мәгълүмати ярдәм күрсәтә;

8) чемпионатта катнашу өчен заявкаларны карап тикшерә;
9) бирелгән заявкалар буенча катнашучылар исемлеген раслый;
10) чемпионатның җиңүчеләрен һәм призерларын бүләкләүне оештыра;
11) чемпионат материалларын анализлый һәм гомумиләштерә;
12) чемпионат турында нигезләмәне «5 нче балалар һәм яшүсмерләр иҗаты үзәге» МАӨББУ сайтында урнаштыра https://edu.tatar.ru/n_chelny/page1585.htm, аны «Татарстан Республикасында электрон мәгариф» (edu.tatar.ru) порталына урнаштыру өчен электрон почта аша белем бирү оешмаларына җибәрә.
13) экспертлар составын формалаштыра.
12. Экспертларның функцияләре:
1) чемпионатта катнашучыларның эшләрен бәялиләр;
2) чемпионатның һәрбер компетенциясендә җиңүчеләрне билгелиләр;
3) йомгаклау беркетмәсен имзалау процедурасын гамәлгә ашыралар. Экспертларның карары ахыргы булып тора, нәтиҗәләрне апелляцияләү каралмаган.
13. Чемпионатта катнашучылар:
1) чемпионатта гомуми һәм өстәмә белем бирү оешмаларының 14-16 яшьлек укучылары катнаша. WorldSkills Russia милли чемпионаты финалын үткәрү датасына конкурсантның яше 16 яшьтән артмаска тиеш;
2) укучылар конкурс биремнәрен үтәү өчен кирәкле белемнәргә һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш.
14. Чемпионат белем бирү оешмасыннан һәрбер сайлап алынган компетенциягә катнашучыны яки команданы әзерләгән бер эксперт (алга таба – ББО эксперты) катнашуны күздә тота.
15. ББО экспертының хокуклары һәм җаваплылыгы:
1) катнашучы белән административ җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра һәм чемпионатны оештыручылар алдында аның мәнфәгатьләрен яклый;
2) аның белем бирү оешмасының катнашучылары белән куркынычсызлык техникасы буенча инструктаж үткәргәндә мәйданчыкта була;
3) белем бирү оешмасыннан килгән барлык катнашучыларны контрольдә тоту һәм аларның чемпионатта үз-үзләрен тотуы өчен җаваплы;
4) чемпионат чараларын уздыру вакытында балаларның гомере һәм сәламәтлеге өчен тулы җаваплы.
16. Катнашучы конкурс биремен үтәгән вакытта конкурс участогында бары тик экспертлар гына була ала.
17. Конкурс участокларын төзүнең гомуми планы кунакларның һәм тамашачыларның чемпионатның барлык конкурс участоклары арасында каршылыксыз йөрүен тәэмин итәргә тиеш.

## 6 бүлек. Башкарылган биремнәрне бәяләү критерийлары

18. Һәрбер компетенция өчен критерийларны тасвирлау оештыру комитеты тарафыннан конкурс биремнәре расланганнан соң гамәлгә ашырыла һәм катнашучыларга җиткерелә.

## 7 бүлек. Чемпионатка йомгак ясау, җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү

19. Чемпионатка йомгак оештыру комитеты тарафыннан ясала, карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.
20. Чемпионатның җиңүчеләре (1 урын) һәм призерлары (2,3 урын) чемпионатның һәрбер компетенциясендә билгеләнә һәм дипломнар һәм бүләк сертификатлары белән бүләкләнә.
21. Җиңүчеләр һәм призерлар арасына кермәгән катнашучылар чемпионатта

катнашучы дипломнары белән бүләкләнә.

22. Экспертлар Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнәләр.

23. Чемпионатның йомгаклары «5 нче балалар техник иҗат үзәге» МАӨББУ сайтында чемпионат тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә басылып чыга.

24. Квоталар булганда, чемпионатның җиңүчеләре һәм призерлары «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) региональ чемпионатында катнаша.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева